(1,1) -1- 5084.indd 06.10.2017 15:38:09

БҮГЕНГЕ САНДА: «8 июль - Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне»

# ТЕЛӘЧЕ

Иҗтимагый – сәяси газета

7 июль, 2017 ел Җомга

2001 елның гыйнварыннан бирле чыга № 49 (1546)

8 июль төнлә - 10 градус, көндез - 18 градус җылы, яшенле яңгыр

(ТЮЛЯЧИ)

РЕСПУБЛИКА ПРОГРАММАЛАРЫ – ГАМӘЛДӘ

## ҮЗӘКТӘ СУ КЫТЛЫГЫ БЕТӘЧӘК

**Соңгы елларда республикабызны барлык юнәлешләрдә дә вакытны узып эшләүче, үсеш юлыннан баручы төбәк итеп күрсәтә башладылар. Бу очракта республикада утыз уникаль программа эшләп килүен әйтеп узу да җитә. Алар ярдәмендә авылларыбызда мәктәпләр, балалар бакчалары, мәдәният йортлары, клублар, спорт мәйданчыклары төзелә, юллар салына һәм төзекләндерелә. Шулар арасында тагын бер колачлысы бар: ул "Чиста су" республика программасы.**



Фотолар www.tulachi.ru сайтында.

- БЕЗГӘ ЭШ КҮЛӘМЕ, АНЫ БАШКАРУ СРОКЛАРЫ БИЛГЕЛЕ. ШУҢА КҮРӘ НИНДИ ҺАВА ТОРЫШЫ БУЛУГА КАРАМАСТАН, АНЫ КЫСКА СРОКЛАРДА ҺӘМ СЫЙФАТЛЫ ИТЕП БАШКАРЫП ЧЫГУ БУРЫЧЫ ТОРА, - ДИ ҮЗ ЭШЛӘРЕНЕҢ ОСТАЛАРЫ БУЛГАН "АЛЬТАИР" ЕГЕТЛӘРЕ

Быел җәй көне әлеге программа нигезендә Теләче, Үзәк авылларына су башнялары куелды. Бу көннәрдә Казанның җаваплылыгы чикләнгән "Альтаир" ширкәте төзүчеләре Үзәк бистәсенең күп балалы гаиләләр өчен бүлеп бирелгән Тукай урамына суүткәргечләр суза. Төзелеш бригадасы җитәкчесе Сергей Жуков белдергәнчә, яңа башнядан су Тукай урамыннан тыш, бистәнең башка урамнарына да җибәреләчәк.

- Яңа башня җәйге чорда бистә халкын җитәрлек су басымы белән тәэмин итәчәк. Алдагы елларда эссе көннәрдә бистә халкы, басым түбән булу сәбәпле, гел су кытлыгы кичерә иде. Мәгълүм программаның озак еллар дәвамында гамәлдә булуы республика, бигрәк тә авыл халкы өчен зур ярдәм һәм казаныш. Моның өчен республика, район җитәкчелегенә рәхмәттән башка сүз юк. Мондый күләмле чыгымнарны бер генә авыл җирлеге дә, халык җилкәсе дә күтәрә алмас иде, - дип үзенең уй-фикерләре белән уртаклашты Үзәк авыл җирлеге башлыгы Вальтер Котников.

Халыкның тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән мондый программалардан районыбызның бер елны да читтә калганы юк. Алдагы елларда әлеге программа нигезендә Әбде авыл җирлегенә кергән Тактамыш, Олы Нырсы авыл җирлеге биләмәсендә урнашкан Кече Нырсы һәм Үзәк авыл җирлегендәге Сауш авыллары урамнарына искеләре урынына яңа суүткәргечләр сузылды, йортларга су кертелде.

- "Альтаир" ширкәте төзүчеләре көннәр явымлы дип тормый, алар көн дә җитештерүчән хезмәттә. Эшне графикка сыешып төгәлләрләр дигән ышаныч бар, - диде, төзүчеләрнең хезмәтенә югары бәя биреп, җирлек башлыгы Вальтер Котников.

Илебез төбәкләренең үсешенә бәя биргәндә, иң мөһим күрсәткечләрнең берсе булып тормыш сыйфаты тора. Яшәешебезгә менә шул яктан килеп караганда, башкалабыз Казан һәм республикабыз Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән һәм өлкәләреннән генә калыша торгандыр. Ә сыйфат дигәнең зур мәгънәгә ия төшенчә. Тормыш сыйфаты экологик чиста әйләнә-тирә мохитне, шәхси иминлекне дә һәм башка төрле күрсәткечләрне үз эченә ала. Районыбызның Үзәк бистәсендә республика программасы нигезендә башня куеп, суүткәргечләр сузып ятулары - моның гап-гади бер мисалы. Шуңа күрә ил-җир күргәннәр, дөнья гизгәннәр туган җиребездә яшәүнең уңайлы булуы турында да шунда ук әйтеп бирер. Хакыйкать чагыштыруда туа, диләр бит. Моны аңлау, тою һәм чагыштыру өчен чит төбәкләрдә булып кайту да җитә. Соңгы елларда булырга туры килгән Әстерхан һәм Чиләбе өлкәләрендә моны мин ачык күрдем, тойдым.

Фәнил НИГЪМӘТҖАНОВ.
Автор фотосы.

КИЧӘГЕ ПОЧТАДАН

## ҖӘЙ ФАСЫЛЫ

Җылы булганга, җәйне яратам,
Бу шигырем дә җәйгә карата.
Бар тараф матур, яшел күлмәктән,
Ихлас соклану чыга йөрәктән.

Җәй шау-чәчәкле! Аның төп яме -
Көтеп алынган Сабан бәйрәме.
Җәйнең ямьнәре тагын бар әле,
Аланы тулы җир җиләкләре.

Мул сулы елга ярында комлык -
Нинди гүзәллек, нинди хозурлык!
Җылы яңгыры, йомшак җилләре,
Күзне иркәләп үскән гөлләре...

Җәйгә бигрәк тә без шатланабыз,
Бу озын ялны көтеп алабыз.
Җәй - табигатьнең шатланган чагы,
Бар фасыллардан яратам аны.

Резедә Шәйдуллина.
Сауш авылы.

ХӘБӘРЛӘР

## САБАНТУЕНА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Зәй шәһәре янында булган куркыныч юл һәлакәтеннән соң Татарстан Республикасы Президенты Указы белән узган якшәмбедә республикада матәм көне игълан ителеп, шәһәр һәм районнарда булырга тиешле Сабантуйлар бер атнага кичектерелгән иде. Район үзәге – Теләчедә Сабантуе 8 июль көнне узачак. Бәйрәм 10.00 сәгатьтә башлана. Хөрмәтле райондашлар, районыбыз кунаклары, бәйрәм программасы белән "Теләче" газетасының 47 санында (30 июнь, 2017 ел) һәм **www.tulachi.ru** сайтында таныша аласыз. Теләче Сабантуена рәхим итегез!

## ФОЛЬКЛОР КЫЗЫКСЫНДЫРА

Узган атнада районыбызда музыкаль-этнографик экспедиция белән Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыкология кафедрасы доценты, сәнгать белгече Генадий Макаров җитәкчелегендә бер төркем мөгаллимнәр һәм студентлар булып китте. Алар керәшен карендәшләребез гомер итүче авылларда булып, музыкаль фольклор, йола һәм дини бәйрәмнәр турында мәгълүмат тупладылар.

## КҮЧМӘ УТЫРЫШТА

Июнь ае азагында балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе эшче төркеменең күчмә утырышы булды. Утырышның көн тәртибендә ике мәсьәлә каралды. Район эчке эшләр бүлегендә тәртипсез яшәү рәвеше алып баручы 16 гаилә исәптә тора. Утырышта алар белән профилактик эш алып бару өчен беркетелгән комиссия әгъзалары узган ярты елдагы эшчәнлекләренә хисап тотты. Соңыннан районның мәшгульлек үзәге җитәкчесе Айдар Галимҗанов җәйге чорда укучыларның кайда эшләүләре белән таныштырды.

## ӘЗЕРЛЕКЛӘРЕ ЮГАРЫ

Узган атнада районыбыз мәдәният хезмәткәрләре, оешма-предприятиеләрдә эшләүче райондашларыбыз Теләче Сабантуенда күрсәтеләчәк массакүләм күренешләрдә (ул ел саен зур оешканлык һәм камиллек белән уза!) катнашу өчен репетициягә йөрде. "Бу эшкә күпчелек райондашларыбыз, оешмалар һәм мәктәпләр намус белән карады. Арада бер көн дә калдырмыйча йөрүче укучылар, мәктәпләр булды. Шундыйлар рәтенә Югары Кибәхуҗа, Олы Мәтәскә урта мәктәпләрен кертергә мөмкин", - дип хәбәр иттеләр безгә район мәдәният бүлегеннән.

## "ЕФӘК ЮЛ" УЗА

9 июль көнне районыбыз аша "Ефәк юл" дип исемләнгән халыкара ралли узачак. Шул сәбәпле, 9 июль көнне 03.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр "Мәскәү-Уфа М7" юлының Олы Нырсы һәм Шәтке авыллары җирлекләренә кергән өлешендә автотранспорт хәрәкәте чикләнәчәк.

Хөрмәтле транспорт йөртүчеләр, бу көнне хәрәкәт итү өчен башка маршрут сайлавыгыз сорала. Юл-транспорт фаҗигаларын булдырмау һәм кисәтү максатыннан әлеге биләмәләрдә транспорт белән хәрәкәт итмәвегезне, автомобиль куймавыгызны үтенәбез. Бу хакта тулырак мәгълүматны Интернет челтәреннән һәм районның рәсми сайтыннан алырга була.